**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **24.11.2022 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Югары Стәрле авыл җирлегенә
керүче Түбән Стәрле авылында 2023 елда
үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегендә халык җыены карар бирэ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- Түбән Стәрле авылында юлларны кардан чистарту ( килешү буенча түләү) ;
-Түбән Стәрле авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (территорияләрне чүп үләннәреннән, корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, агачлар һәм куаклар, чәчәкләр утырту , килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәтләре күрсәтү).

3. Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Югары Стәрле авылы, Совет., 32г йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы: Сабиржанова Л.С.